Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Янил авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

2024 елның 15 ноябре №7

«Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Бөяр авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 28 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Бөяр поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Бөяр поселогы, Чәчәкле ур., 5 йорт адресы буенча урнашкан торак йортта үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Бөяр поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Бөяр бистәсенә энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Бөяр бистәсендә урам юл челтәрен карап тоту, проект-смета документларын эшләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Янил авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х. Корбанов